Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 декабрь 2021 ел № 109

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләргә тапшыру турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, «Әлмәт муниципаль районы үзидарә органнары белән Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләр белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру тәртибе (кабул итү) турындагы килешүе хакындагы»гы Әлмәт муниципаль район Советының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләргә тапшыру турында»гы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 карага 1 пунктта «үзгәрешләр кертү өлешендә» сүзләреннән соң «(әзерлек һәм эшләмә)» сүзләрен өстәргә;

1.2 карага 1 нче кушымтаның «Килешү предметы» бүлегендә «үзгәрешләр кертү өлешендә» сүзләреннән соң «(әзерлек һәм эшләнмә)» сүзләрен өстәргә;

1.3 килешүгә кушымтаның 1 пункты «үзгәрешләр кертү өлешендә» сүзләреннән соң «(әзерлек һәм эшләнмә)» сүзләрен өстәргә.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлмәт муниципаль районы Башлыгы урынбасары М.Н. Гирфановка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов